| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2021 Казан ш. № 345-13/э-2021

«Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-8/э карары белән билгеләнгән озак сроклы индивидуаль тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының кирәкле тулай табышына 2022 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2020-2024 елларга индивидуаль тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-8/э карарына (Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитетының 25.11.2020 № 273-9/э-2020 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-8/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2021 № 345-13/э-2021 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2020 | 664 335,08 | 139,86 | 1,68498 | 664 335,08 | 139,86 | 1,68498 |
| | | 2021 | 736 452,26 | 163,65 | 1,87863 | 736 452,26 | 163,65 | 1,87863 |
| | | 2022 | 728 770,21 | 163,53 | 1,85834 | 728 770,21 | 163,53 | 1,85834 |
| | | 2023 | 689 118,51 | 148,37 | 1,75113 | 689 118,51 | 148,37 | 1,75113 |
| | | 2024 | 709 792,07 | 152,82 | 1,80367 | 709 792,07 | 152,82 | 1,80367 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 3-8/э карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2021 № 345-13/э-2021 карары
редакциясендә) 2 нче кушымта

2020-2024 елларга (югалтуларны исәпкә алмыйча) «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең кирәкле тулай табышы

| Т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы | 2020 | 24 792,99 |
| | | 2021 | 25 982,04 |
| | | 2022 | 22 856,85 |
| | | 2023 | 25 717,90 |
| | | 2024 | 26 489,44 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге